Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Ямаши авыл җирлегенең
Ямаши авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы карары

21 ноябрь 2024 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2024 елның 21 ноябрендә 17 сәгать 00 минутта узган гражданнарның этаплы җыен нәтиҗәләре нигезендә түбәндәге «Сез 2025 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Ямаши авыл җирлеге Ямаши авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү, мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылганнардан, вакытлы хезмәт узу өчен яисә Россия Федерациясе Оборона министрлыгы белән контракт төзегән гражданнардан тыш һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрүгә юнәлдерү белән килешәсезме: су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (су белән тәэмин итү челтәрләрен алмаштыру)?" соравы буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 493 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 258 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында катнашучыларның 258 «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде; катнашучыларның 0 «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Мәмәт авыл җирлегенең Мәмәт авылында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - чынбарлыкка туры килә.

2. "Сез 2025 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Ямаши авыл җирлеге Ямаши авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү, мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылганнардан, вакытлы хезмәт узу өчен яисә Россия Федерациясе Оборона министрлыгы белән контракт төзегән гражданнардан тыш һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрүгә юнәлдерү белән килешәсезме: су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (су белән тәэмин итү челтәрләрен алмаштыру)?» турындагы мәсьәлә буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Ямаши авылы, Совет урамы, 4 йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат- телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Ямаши авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Ямаши авыл җирлеге башлыгы А.А. Андревкина